Татарстан яшьләре

№ 27

(8749)

ПӘНҖЕШӘМБЕ

4 март, 1993 ел

Бәясе килешү буенча.

* ЯШЬЛӘРНЕҢ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ * 1920 ЕЛНЫҢ 22 ГЫЙНВАРЫННАН БИРЛЕ ЧЫГА *

Бер хәбәр уңаеннан

Президентка сабак бирделәр

"Вечерняя Казань" газетасы Татарстан парламенты сессиясе ачылуга зур "бүләк" әзерләгән иде.

Президент М.Шәймиевнең улын тоткарлауда катнашкан аноним авторның хаты Татарстанда зур шау-шу куптарыр дип өметләнгән журналистлар бу юлы ялгыштылар.

Хәбәрнең бер айга соңарып - нәкъ менә сессия ачылган көнгә туры китереп басылуы үзе үк нинди максаттан чыгып эшләгәнлекне күрсәтә. Бу мәсьәләне куертып җибәрергә тырышучы депутатлар да парламентта яклау тапмады. Президент исә үзенә хас салкын канлылык белән бу хәлнең махсус эшләнгән әйтте. Моңа милиция хезмәткәрләренең ?-ләрен ничек тотуы һәркайсыбызга мәгълүм икәнлекне дә өстәсәң, бу сенсациянең ни өчен барып чыкмаганлыгы яхшы аңлашыла.

Сүзне шуның белән түгәрәкләргә дә мөмкин булыр иде. Ләкин Президентның берничә тәртип бозмаган улын мәсхәрә итәргә һәм тоткарларга осталыгы җиткән милициянең безнең теләсә кайсыбызны акылга утыртырга гына кулыннан килми дип кем әйтә ала. Россия буйсынуындагы тәртип сакчылары иртәгә тагын шундый яки тагын да кәттәрәк хәл оештырмавына да ышанып булмый. Бәлки нәкъ менә шушы хәлдән соң Президент һәм Югары Совет хокук саклау органнарын Татарстан юрисдикциясенә күчерүнең никадәр мөһим һәм хәлиткеч мәсьәлә булуын аңларлар.

***

Татарстанның Тышкы икътисадый элемтәләр министрлыгында (ТИЭМ) "Татарстан-Саксония" дип исемләнгән комиссия төзелде. Аның җитәкчесе итеп ТИЭМның стратегик планлаштыру бүлеге мөдире В.Попов билгеләнде.

Алманнар - Татарстанда иң актив эшмәкәрләр. Нилектән?

ТИЭМда Саксония кунаклары ешайды. Мәсәлән, 25-27 февральдә Саксония хөкүмәтенең киңәшчесе профессор Дитер Борман булып китте. Ул бездәге хәл белән якыннан танышу өчен килгән иде. Ә 12 февральдә Берлинда ТИЭМ делегациясе икътисадый тикшеренүләр буенча немец институты (ИТНИ) вәкилләре белән очрашты. Нәтиҗәдә ниятләр турында беркетмәгә кул куелды.

"Т.Я." алманнарның чит ил эшмәкәрләре арасыннан иң актив икәне турында язган иде инде. Шуңа тагын бер дәлил: бүген ТР туфрагында ГФРның 25 фирмасы үз эшчәнлеген алып бара. Кайберләре Казанда үз вәкиллекләрен дә ачарга өлгерде инде. Алманнарның актив булуларының сере дә ачылып килә. Баксаң, ГДР белән ГФР кушылгач, элек социалистик ярыш рухында эшләгән предприятиеләрнең товарларын Көнбатыш базарына чыгара башлаганнар икән. Ләкин анда сорауга караганда тәкъдим күбрәк бит, ә бездә киресенчә. Шуңа күрә дә Саксония җире хөкүмәте тәртәләрен Көнчыгышка таба борган. Элеккеге СССРны яхшылап өйрәнгәч, иң тотрыклы дәүләтләр сайлап алына. Алар: Татарстан, Казахстан һәм Башкортостан.

ТИЭМда, бу уңайлы форсаттан файдаланып, икътисадый килешүләрне киңәйтеп җибәрергә уйлап торалар. Саксониядә һәм Татарстанда вәкиллекләр ачу планлаштырыла.

Равия САБЫР.

***



Кыш буе алма, әфлисун, лимон ише җәй җимешләреннән өзелмәгән Татарстан халкы алга таба да яшелчә һәм җиләк-җимеш ашап рәхәтләнергә мөмкин. Татарстан белән Кырым арасында төзелгән сәүдә-икътисадый хезмәттәшлек турындагы килешү буенча республикага АПК өчен технологик җиһазлар белән бергә яңа өлгергән җиләк-җимеш, яшелчә, йөзем, шәраб һәм башка халык куллануы товарлары кайтарылырга тиеш. Ә Татарстан исә Кырымга полиэтилен, "КамАЗ" машиналары, шиннар, ягулык кебек товарлар җибәрәчәк.

Татарстанга эшлекле элемтәләр урнаштырырга дип килүчеләр сафына тагын берничә чит ил эшмәкәре өстәлде. 2 мартта вице-президент В.Лихачев америка "Халим Интернэшнл" компаниясенең президенты һәм генераль директоры Әмир Х.Соас әфәндене кабул итте. Кунак Оклахома штаты җитәкчелеге һәм эшлекләләре исеменнән Татарстан белән ике арада элемтәләр урнаштырырга теләкләре булуын белдерде һәм М.Шәймиевкә штатның вице-губернаторыннан хат тапшырды.

Экспертлар Татарстанда яшәүчеләрнең уртача хезмәт хакы апрель аенда 25-30 мең тәшкил итәчәк дип әйтәләр. Моны премьер-министр Р.Моратовның бездәге халык Россиядәгеләрдән зуррак хезмәт хакы алачак дип ышандыруын тагын бер кат дәлилләргә тырышу гына түгелдер дип аңларга кирәк.

Казандагы сәүдә "генералларының" кайберләре урыннары белән хушлашырга мөмкин. Вице-премьер һәм Казан шәһәре администрациясе башлыгының кибетләрдә йөреп чыкканнан соң: "Кирәк булса, тулы коллективларны да алыштырырбыз", - дип белдерүе сәүдә өлкәсендәге башбаштаклыкка чаралар күрелә башлауга нигез булырга мөмкин.

Быелның 9 мартында "Казан" милли-мәдәни үзәгендә Татарстан иҗтимагый оешмалары делегатларының конференциясе уздырыла. Көн тәртибендә берләштерелгән оешмаларның җитәкче органын сайлау күздә тотыла. Конференция 18 сәгатьтә башлана.

Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә кандидатлар тәкъдим итү дәвам итә. Әлегә бу бүләккә язучылар Гомәр Бәширов, Нурихан Фәттах, Разил Вәлиев һәм Ренат Мөхәммәдиев дәгъва итә.

Югары Совет сессиясендә бик соңарып булса да яшьләр турында Закон кабул ителде. Бу уңайдан Президент тәкъдиме белән Балалар һәм яшьләр эшләре буенча дәүләт комитеты оештыру турында карар чыгарылды.

***

ТАТПРОМСТРОЙ



Без дә эшли беләбез!

Татарстан Республикасының Сәнәгать-төзелешне үстерү Акционерлык банкы (Татсәнтөзбанк) югары дәрәҗәле халыкара банк статусына ирешүдә соңгы адымын ясады. Моңа кадәр ул чит ил банклары белән эшләүгә лицензия алуга ирешә, җир шарының теләсә кайсы ноктасына спутник аша элемтә булдырды, дөнья банклары арасында үзенең абруен күтәрү өстендә эшләде. Һәм менә бу көннәрдә Татсәнтөзбанк банкларның халыкара финанс бәйләнешләре системасына (SWIFT) керүе турында белдерде. Моны раслаучы лицензия инде алынган.


Нәрсә ул SWIFT? Иң яхшы банкларны берләштергән һәм дөньяда бердәнбер булган әлеге система банклар арасында мәгълүмат тапшыруның һәм исәп-хисап ясауның югары тизлеген тәэмин итә. SWIFT системасына керүче дөньяның теләсә кайсы банкы белән валюта операцияләре 5-10 секундта, ә башка банклар белән күп дигәндә 20 минутта башкарыла. SWIFT шулай ук мәгълүматларның серлелеген гарантияли, аларның дөреслеген һәм тулысынча автоматлаштырылуын тәэмин итә. Бу максатларда банк якын көннәрдә 200 мең долларга Англиядән махсус җиһазлар сатып алачак. SWIFT системасының әгъзасы булу банкка тагын да кыйммәткә төште - моның өчен 1800 мең бельгия франкы күләмендә керү взносы түләргә туры килде.

Тотылган чыгымнарны санау бирегә урынсыз, чөнки SWIFT системасына керү һәрбер банк өчен бик дәрәҗәле вакыйга. Хәзергә вакытта бу системада дөньяның 80 иленнән 3 меңгә якын финанс оешмасы әгъза булып тора. БДБ да мондый банклар нибары 6. Ә Татсәнтөзбанк Республикабызда гына түгел, бөтен Идел буе регионында бердәнбер шундый банк. Әлбәттә, Республикабыз өчен бик уңайлы факт бу. Татарстанга чит илләр белән элемтәгә керүдә, финанс бәйләнешләрен җәелдерүдә, валюта исәп-хисаплары ясауда искиткеч әйбәт мөмкинлекләр ачыла. Татсәнтөзбанк идарәсе рәисе Рафаэль Минһаҗев: "Нәрсә генә эшләсәк тә, безнең төп максат - Татарстан суверенитетын реаль эшләр белән тулыландыру", - дип белдерде.

Әйе, банкирга ышанырга, ә аның коллегаларының эшчәнлегенә сокланырга гына кала. Алар нәрсәдер булганны көтмиләр, ә эшләргә тырышалар һәм эшли дә беләләр. Бу җәһәттән башка банкларга Татсәнтөзбанкның эшчәнлеген, шул исәптән журналистлар белән эшләү алымнарын өйрәнәсе дә өйрәнәсе әле.

Рәис НАСЫЙБУЛЛИН.

***



Рәсемдә:

Гайфуллина Әсфирә Гали кызы. Ул Татарстан чемпионатларында һәм "Себер бәйрәме" чаңгы ярышларында күп мәртәбә җиңүләр яулады. 4-12 февральләрдә Норвегиянең Гейло шәһәрендә үткәрелгән Осталар Кубогы чемпионы. Әлбәттә инде, ветераннар арасында.

Икенчесе - Игорь Максимов. Казан егете. Күптән түгел генә Польшаның Закопанесында үткәрелгән Бөтендөнья студентлар универсиадасының чаңгы эстафетасында (4х10 км) чират буенча икенче йөгереп, команда составында беренче урынны яулады һәм халыкара класслы чаңгы остасы нормасын үтәде.

Е.КАНАЕВ фотосы.

***

"Табиб киңәш итә"

Шушы исем астында һәр җомга көнне медицина институтының Актлар залында төрле темаларга әңгәмәләр үткәрелә. Кичәләрнең оештыручысы - Татарстанның Ислам табиблары берләшмәсе. Әңгәмәләр вакытында сихәтләнүнең яңа ысуллары турында сөйләнә. 5 март көнне, мәсәлән, медицина фәннәре докторы Әлфия Ибраһимова курортларда һәм санаторийларда дәвалану турында чыгыш ясаячак.

***

Сум акрынлап әйләнешкә керә

Казанның "Детский мир" кибетендә яңа киоск эшли башлады. Аны "Кари" фирмасы ачкан. Ә фирма үзе Татпромстройбанк системасына керә. Әгәр сумның чынлыкта күпме торганын беләсегез килсә, "Детский мир"га барып карагыз. Бүген анда валюта белән сату итәләр. Мәсәлән, АКШ доллары 680 сумнан сатып алына һәм 745 сумнан сатыла. Германия маркалары исә, 410 нан сатып алына һәм 470 сумнан сатыла.

Бүгенгә "Детский мир"да балалар товарларын бик тырышып эзләсәң табарга була әле. Киләчәктә валюта кибетенә әйләнмәсен инде берүк.

Рөстәм КИРАМОВ.

***

Конкурс! * Конкурс! * Конкурс! *

Журналист буласың килсә...

"Дөньяда иң абруйлы һөнәр - журналист" дип язганда, без бу хакыйкатьне үзебез генә беләбездер дип уйлаган идек. Баксаң, бу турыда мәктәп укучылары да хәбәрдар икән. "Т.Я." үткәрә торган "Журналист буласың килсә" конкурсына дистәләрчә хатлар килде. Тиздән аларның иң яхшылары басылып чыгачак. Конкурс дәвам итә! Беренче өч урынны алган авторлар Казан дәүләт университетының журналистика факультетына имтихансыз нисез керәчәк.



Исәнме, "Әй"! Чит илләрдәге яшьтәшләрем кебек минем дә берничә тел беләсем килә. Еллар буе түгел, ә бәлки санаулы ай эчендә генә тел өйрәнергә мөмкин микән?

РУШАНИЯ.
Лаеш районы.

Тел белгән югалмас

Бөтендөнья тел белгечләренең соңгы елларда үткәрелгән конгрессында хәзерге вакытта кешеләрнең 3000 гә якын телдә сөйләшүе турында хәбәр ителә. Кайбер телләрдә миллионлаган кешеләр сөйләшә, ә кайберләрендә - берничә йөз. Дөньяда яшәүче кешеләрнең күбесе кытай телендә сөйләшә (1 миллиардтан артык). Инглиз теле дә популяр. Бу телне 350 миллионнан артык кеше куллана һәм ул хәзерге заманда иң "модалы" телләрнең берсе санала.

Берничә тел белүчеләрне полиглот дип атыйлар. Кардинал Меццофанти (1774-1849) 100 гә якын тел белгән. Немец теле белгече Л.Г.Шютц ~270 телдә сөйләшә алган. Копенгагеннан Р.Х.Раск та аннан аз гына калышкан. Ул бөтен дөньяны әйләнеп чыккан, 230 тел белгән һәм 28 сүзлек төзегән.

Әйе, бу кешеләр аеруча талантлылар. Әмма теләге булган һәр кеше берничә тел өйрәнә ала. Балалар чит телләрне аеруча тиз һәм җиңел үзләштерәләр.

Тел өйрәнүгә карата полиглотларның фикере мондый: "Фикерегезне үзегез өйрәнгән телдә җиткерергә тырышыгыз".

Икенче шарт: бик нык кызыксынучан булыгыз, шул телне белүчеләр белән күбрәк аралашырга тырышыгыз.

Һәм өченчесе: күбрәк музыка тыңлагыз, ишетү сәләтегезне үстерегез. Ишетү сәләте - чит телне өйрәнүдә иң яхшы ярдәмче.

Телне өч төрле юл белән өйрәнергә мөмкин. Мәсәлән, укытучы әйберләрнең исемнәрен атый, ә укучы сүзләрне истә калдырганчы кабатлый. Бу метод белән бер телне якынча 200 сәгать өйрәнергә мөмкин.

Икенче ысул - магнитофон ярдәмендә. Аны төгәл аңлатма биргән кулланма ярдәмендә тыңлыйлар.

Иң киң таралган ысул - тизләтелгән метод. Ул грамматика, тел үзенчәлекләрен өйрәтүне максат итеп куймый. Иң мөһиме - сөйләшергә мәҗбүр итү. Атнага өч сәгать вакыт теориягә, калганы - сөйләм телен үстерүгә багышлана.

Мәсәлән, урыс телендә ярты миллион сүз бар. Ә практикада күпме сүз кулланыла?. Хәтта Пушкин булып Пушкин да фәкать 22 мең сүз генә файдаланган. Шуңа күрә иң мөһиме - аеруча күп кулланыла торган сүзләрне өйрәнү. Чит телдә иң еш кулланыла торган ике мең ярым сүзне өйрәнсәң, шул телдә китап укый башларга мөмкин.

Ә хәзер чит тел өйрәнүчеләр белергә тиешле иң мөһим 10 кагыйдәне искә төшерик:

1. Өйрәнү даими булырга тиеш. Атнага бер тапкыр берничә сәгать укуга караганда, аз-азлап һәр көнне өйрәнү яхшырак.

2. Үзең белән һәрвакыт сүзләр, кагыйдәләр, текстлар язылган куен дәфтәре йөрт.

3. Дәресләрнең формасын төрләндер: укы, аннан тыңла, грамматика өйрән, яз һ.б.

4. Бирелгән тексттагы сүзләрне өйрән.

5. Текст авыррак аңлашылса да, мөмкин кадәр күбрәк укырга тырыш.

6. Булдыра алганча ятла.

7. "Әйтергә кирәк", "игътибарыгызны шуңа юнәлтәм", "минемчә", "уйларга вакыт бирегез" кебек сүзләрне күбрәк өйрәнегез, алар алдагы фразаны әйтер алдыннан уйланырга мөмкинлек калдыралар.

8. Тел - ныгытма (крепость), шуңа аны төрле яктан яулап алырга тырышырга кирәк. Практика - уңышның нигезе. Кечкенә генә мөмкинчелекне дә кулдан ычкындырмагыз.

9. Хаталардан курыкмагыз. Хата ясамыйча гына өйрәнеп булмый! Артык кыюсызлык бу очракта ярдәм итми, ә үз-үзеңә ышануның зыяны юк.

10. Буш вакытыгызны әрәм итмәгез. Шәһәр транспортында йөргәндә, кемнедер көткәндә дә сүзләр ятлый торыгыз.

Бу кагыйдәләрне үтәгән һәм теләге булган һәркем полиглот була ала.

Кемгә сөйлим серләремне?

Яшисе килә

Исәнме "Әй"! Мин быел мәктәпне тәмамлыйм. Авыл тормышын бик яратсам да, китәргә туры килер инде. Армиядәге вәхшилекләр турында укыганнан соң ничек булса да солдатка бармаска дигән нәтиҗәгә килдем. Шуңа күрә берәр институтка укырга керергә исәплим. Армиядән качып кына студент булып йөрүне үзем дә хупламыйм, әмма, нишлисең, яшисе килә бит.

НАДИР.
Бөгелмә районы.

Үз акчаңа ни җитә?

Америкадагы яшьтәшләремнең мәктәптән соң төрле җирләрдә акча эшләүләре турында укыганым бар. Ә нигә бездә дә шундый мөмкинчелекләр юк икән? Минем дә үз акчамны булдырасым килә. (Әти-әнидән күпме сорарга була инде?!)

РИММА.
Казан.

Йөрәгемне алып киттең...

10 январь көнне Чаллы - Ижевск поездында бер егетне күзәттем. Ул сеңлесе белән иде. Аларның сөйләшүләреннән егетнең Ранис, сеңлесенең Миләүшә икәнен белдем. Ранис, минем үзенә карап баруымны сизеп, үзе дә миңа күз төшергәләде. Безнең күзләребез очрашты, ләкин эндәшергә беребезнең дә кыюлык җитмәде. Алар Әгерҗе станциясендә төшеп калдылар. Егет йөрәгемне дә үзе белән алып китте. Шул көннән бирле тынычлыгым югалды. Ранис, бәлки син дә мине хәтерлисеңдер? Мин тагын сине очрату өмете белән яшим. Әгәр дә син бу хатны укысаң һәм мине исеңә төшерсәң, хат яз.

МӘРЗИЯ.
(Адресым редакциядә.)

Авызыма аракы хуҗа

Сәлам, "Әй"! Мин аракыны беренче тапкыр 14 яшьтә авызыма каптым. Күрше егетен армиягә озатканда кыстый-кыстый эчерттеләр. Шуннан китте инде... Үзебезнең компаниябез бар. Егетләр белән эчәргә сәбәп чыгып кына тора. Йә танышу хөрмәтенә күтәрәбез, йә дискотека алдыннан салабыз, йә туган көнне билгеләп үтәргә туры килә. Кечерәк чакта "эчүен ташлый алмый" дигән сүзгә көлеп кенә карый идем. Имеш, ничек инде бер авызыңа хуҗа булмаска мөмкин? Ә хәзер аңладым. Төрмәдә гел шул минем кебекләр утырадыр инде. Минем дә иң курыкканым төрмә...

РАДИК, 16 яшь.
Түбән Кама шәһәре.

Мин "өстерәлчек" түгел

Мин авылны яратам. Тик шәһәрдән кайткан кызларга авылның тискәре карашын һич тә аңлап бетерә алмыйм. Егетләр безне "өстерәлчек" һәм тагын әллә кемнәргә тиңлиләр. Авылда туып, шәһәрдә үссәм дә, мин үземне авыл кызы дип саныйм. Ә "өстерәлчекләргә" килгәндә, алар хәзер шәһәрдә дә, авылда да җитәрлек. Мин шәһәрдә яшәүче, татар кызын аңлый торган авыл егете белән хат алышыр идем.

КАЗАН КЫЗЫ.
(Адресым редакциядә).

Төкерәм мин модага

Мәктәп формасын бетерү минем өчен бик авыр булды. Хәзер яшьтәшләремнең күбесе иң соңгы мода белән киенергә тырышалар. Тәнәфес вакытында да кемгә нәрсә алулары хакында гына сүз бара. Минем дә әти-әни бар, алар да эшлиләр, әмма алган акчалары ашарыбызга да җитми.

РАМИЛ.
Әгерҗе районы.

Дин сабагын өйрәтегез

Безнең әти-әниләр, әбибабайлар, ачлы-туклы яшәсәләр дә, бер-берсенә ихтирамлы, ярдәмчел булганнар. Ә хәзер иң тыйнак саналган мөселман халкына да сүгенү, тупаслык, явызлык, мәрхәмәтсезлек кебек тискәре күренешләр хас. Бу, миңа калса, ислам диненә хөрмәт итмәгәннән, белмәгәннән килә. Безнең дин яхшылыкка өйрәтә. Элеккегеләр тикмәгә генә "динсез кеше - денсез кеше" дип әйтмәгәннәр инде. Мәктәпләрдә дә дин сабагы өйрәтелсен иде.

Ф.ФӘХРӘЗИЕВ.
Актаныш районы.

Ләйсән МОСТАФИНА:

"Минем биисем килә!"

Һәрвакыт көләч, эчкерсез Ләйсән сәхнәдә дә шаян булып кала белә. Бәлки шуңадыр, аның биюләрен карaганда күңелдә изгелек эшләү теләге кабына. Матурлык белән очрашканда усаллыкка урын калмый, күрәсең...

- Ләйсән, биюче һөнәре сайлавыңа әниеңнең роле зур булгандыр? (Ләйсәннең әнисе Рузалия Мостафина - Татарстанның атказанган биючесе).

- Биш яшемнән Тезүчеләр культура йортында бию түгәрәгенә йөри башладым, ансамбльнең үз студиясендә шөгыльләндем. Ләкин әни мине биюче итәр өчен тырышмады, үзем дә биюче булып китәрмен дип уйламый идем. Җиденче сыйныфны тәмамлагач дусларым Уфа хореография училищесына укырга керергә әзерләнә башладылар, мине үзләре белән китәргә димләделәр. Диплом алуга Казанга, ансамбльгә әйләнеп кайттым.

- Профессиональ сәхнәгә ничә яшьтә аяк бастың?

- Казанга каникулга кайткан вакытларда концертларда әнине алмаштыра идем. Ул чакта миңа 14 яшь иде.

- Ансамбльгә зур өмет, хыяллар белән кайткансыңдыр?

- Чыннан да шулай. Ни дисәң дә, ул бит минем туган йортым кебек. Кечкенәдән үк әнигә ияреп, чегән баласы кебек гастрольдә йөрдем. Туган йортка эшләргә дип кайттым. Ләкин хыяллар бер мизгелдә челпәрәмә килде. Минеке генә түгел, бик күп кызларныкы.

- Сәбәп?

- Аерым иҗат итү ансамбль ихтыяҗларына туры килми. Ә минем биисем килә! Кеше, беренче чиратта, үз булдыгыннан чыгып эшләргә тиеш. Аерым эшләү җиңел түгел. Монда физик сыйфатлар гына түгел, техник камиллек тә кирәк. Фонограммалар, киемнәр булдыру мөмкинлеге чикле. Барысы да спонсор табуга кайтып кала инде.

- Ләйсән, синең чыгышларың башкаларныкын кабатламый. Бию ничек туа?

- Бию дә шигырь юллары кебек искәрмәстән туа. Син аны күңелең белән аерым тесмерләр, бизәкләр өстәп үстерәсең генә. Чегән биюе нәкъ шулай туды. Бер көнне кич пластинка уйнатам. Көй күңелемне яулап алды, үзем дә сизмичә шәлемне иңемә салып көзге алдында бөтерелергә тотындым. Шул кичне абыем Искәндәр кейне кассетага яздырды, сеңлем күлмәк текте.

- Ләйсән, син бүгенге иҗатыңнан канәгатьме?

- Хәзерге вакытта минем программада 13 бию. Ә күңелдәгеләре бихисап. Максатым - үз программамны булдыру, бөтен дөнья халык биюләрен башкару.

- Киемнәреңне кем тегә?

- Бөтен гаиләбез белән тегәбез. Әнием оста тегүче, кечкенәдән мине дә өйрәтте. Тукымаларны үзебез табабыз. Хәзерге заманда бу бик кыен мәсьәлә. Шуңа иске күлмәкләрдән яңаларын тегәргә туры килә.

- Син гастрольгә еш йөрисең. Чит илләрдә дә булдың.

- Әйе, ансамбльдә ике ай эшләгәч, мине Төркиягә алып бардылар. Моның өчен мин коллективка бик рәхмәтле. Англиягә ике сәяхәт булды. Анда тамашачылар безне үз итеп каршы алды. Ул илләрдә безнең милли биюләр белән кызыксыну бик көчле. Ләкин анда, аеруча Төркиядә, биючелеккә һөнәр дип карау юк, бары күңел ачу итеп кабул итәләр.

- Яраткан шөгылең?

- Йокы. Ләкин ул безгә бик аз эләгә. Буш вакытларда пешерергә, тегәргә, чигәргә миңа куш. Тагын яраткан эшем - балаларның бию түгәрәген җитәкләү. Балалар белән бик дус яшим. Дәресләрдән соң алар хәтта өемә кунакка да киләләр.

- Ләйсән, үз яшьтәшләреңә нинди теләгең бар?

- Алар тормышны аңласыннар, авырлыклар каршында югалып калмасыннар. Бәхетле булсыннар.

Фәгыйлә ГАТУПОВА.

Рәсемдә: биюче Ләйсән Мостафина.
Нурислам ИСМӘГЫЙЛЕВ фотосы.



Булачак солдатларга берничә киңәш

Мин быел яз көне генә армиядән кайттым. Хезмәтемне Украинадагы хәрби берләшмәләрнең берсендә үттем. Анда чыгучы "Солдатская слава" дигән газетаның баш мөхәррире Рафис абый Могыйнов иде. Ул газетаны солдатлар да, офицерлар да зур түземсезлек белән көтеп алалар иде. Газета соңгы елларда армиядә башланган үзгәрешләрне тоткарлаучы командирларны тәнкыйтьләп еш язды. Хәрби журналистларның каләм осталыгына, кыюлыгына соклана идек. Минем үземнең дә хәрби газета битләрендә берничә тапкыр мәкаләләрем басылды. Газета хезмәткәрләре белән дә якыннан таныш идем.

"Татарстан яшьләре"ндә басылган армиягә кагылышлы язмалар минем уйларны яңадан әле берничә ай элек кенә хезмәт иткән частема кайтарды. Солдат тормышын, подразделениеләрдәге хәлләрне аеруча әйбәт белүче кеше язмасы бу. Мин ике ел хезмәт иткән частьта да Рафис абый Могыйнов язмасында телгә алынган тәртипсезлекләр, җинаятьләр булмый калган көннәр сирәк иде. Казармада солдатлар арасында үзара сугышу, урлашу, яшь солдатларны төрлечә җәберләү, мәсхәрә итү очраклары аеруча күп. Подразделениедә андый кыргыйлыкларны башлап йөрүчеләрнең күбесе - армиягә кадәр үк милициядә берничә тапкыр булырга өлгергән хулиганнар. Алар физик һәм рухи яктан йомшак булганнарны гына кыерсыталар. Берничә тапкыр нык каршылык күрсәткәннәрне казарма хулиганнары әйләнеп үтә башлый. Шуның өчен армиягә барырга җыенып йөрүче яшьләргә бер киңәшем бар. Армиягә килгәч күз яшегезне агызып, җебеп йөрмәгез. Кирәк вакытта тиешле каршылык бирергә дә өйрәнегез. Солдат киемен кигән көннән үк чын дусларыгыз да булсын. Шул чагында солдат хезмәте җиңел үтәр, әти-әниегез, туганнарыгыз да зур кайгыга батып, калтырап тормаслар.

Илфат ГАТАУЛЛИН.
Спасс районы,
Ямбакты авылы.

13 нче БАГАНА

Сезгә бер үтенечем бар иде, зинһар миңа бер китап табарга булышыгыз. "Русский язык для 9-11 классов вечерней (сменной) и заочной школы". Авторлары: Л.Ю.Максимов, Л.А.Чешко.

Шул китапны кем дә булса миңа тәкъдим итсә, бик шат булыр идем.

Алдан ук рәхмәт әйтеп, даими укучыгыз.

РЕЗЕДА.

* * *

"Т.Я."ның теләсә нинди санында "Үз тиҗемне котәм" дигән рубрика белән игъланнар чыга. Шул язмада ник берсе язсын мин аракы эчәм дип. Егет халкы эчми дә, тартмый да үз тиңен тапканчы. Аннан, үз тиңен тапкач, айлык хезмәт хакына аракысын да, тәмәкесен дә ташып кына тора инде. Эчмибез дип язсалар да, кибеттә аракы бетеп кенә тора, хәтта спирты да тормый.

Т.Р.А.
Питрәч.

* * *

"Аргамак" журналының 11-12 нче саннарында басылган "Табеев кушышы" дигән язманы шаклар катып укып чыктым. Борынгы заман ханнарының хәрәм-сарайлары турында ишеткән бар иде. Хәзер дә бар икән. Менә безне нинди түрәләр "коммунизмга" таба житәкләп алып барып, капитализмга китерәп чыгардылар!

Ләнар ШӘЙДУЛЛИН.
Актаныш районы,
Татар Ямалысы авылы.

* * *

Телевизорда "Байлар да елый" фильмы беткәннән бирле безгә - гади халыкка бер карар нәрсә калмады. Кайда игълан, кайда реклама, кайда үбеш-кочыш, йокы бүлмәсе, я тереш-кечләү турындагы фильмнар. Бетенесе чит илдән алынган. Хәтта мультфильмнарының да рәте китте. Кая соң безнең үзебезнең ил фильмнары? Күлмәксез-штансызларны күреп туйдык бит инде.


Ф.ГАЛИУЛЛИН,
А.ШӘЙХИЕВ,
Г.ХӨСНЕТДИНОВА,
Н.САТТАРОВА.
Әгерҗе районы.

* * *

Мөхтәрәм "Татарстан яшьләре", сезгә Аму-Дәрья буеннан кайнар сәлам! Кызык өчен сезгә хезмәт хакы алгач бер посылка җибәрмәкчемен.
Әйткән идем бит бер хатымда, үзбәкләрнең сары кишерен яратам дип. Менә шул кишерне сезгә авыз иттерәсем килә. Ризык булса, теш сындырып керер дигән борынгылар. Дөрес, мин сезнең тешне сындырмам, һич югы бер пылау пешереп ашарсыз.

Рәкыя МИНҺАҖЕВА.
Үзбәкстанның
Хорезм өлкәсе,
Дуслык каласы.

РЕДАКЦИЯДӘН.
Тагын берәр укучыбыз ит, сарымсак, дөге җибәрсә, көнбагыш маен базарга чыгып алсак, тоз, борычны өйдән алып килеп булса да пешерәбез без ул пылауны, боерган булса! Рәхмәт сезгә, Рәкыя ханым!



Таныш булыгыз!

Хәзер һәркем яхшы аңлый: кешечә яшәр өчен илебездә икътисадны аякка бастырырга, кыймылдый башларга, дөньяга чыгарга кирәк.

Бүгенге болгавыр һәм болганчык чорда су өстенә чыккан чүп-чар төсле төрле сорттагы вак спекулянтлар, бер көнлек эшкуарлар, җинаятьчел элементлар күбәеп китте. Ләкин шушы ук вакытта куәтле айсберг кебек яңа икътисадый көчләр баш калкыта. Мәйданга милләтебезнең белемле, тәрбияле, мәгълүматлы һәм энергияле яшьләре чыга. Шундыйларның берсе - Махсуслаштырылган җирле "Агропромышленность" инвестиция фонды идарәчесе Марс Мөсгут улы МӨХӘРЛӘМОВ.

Марс - Кукмара егете. Аңа 27 яшь. Ачык йөзле, бик тыйнак һәм әдәпле. 1985 елда Әтнә совхоз-техникумын тәмамлаган.

Аның хезмәт биографиясенең кайбер этаплары: Лениногорск районы совхозында инженер-механик, баш инженер; армия хезмәте; Кукмара һәм Зәй районы комсомол оешмаларында оештыру бүлеге мөдире, беренче секретарь; читтән торып Мәскәүнең халыкара мөнәсәбәтләр институтында уку. Болардан тыш Марс менеджерлар мәктәбен тәмамлаган, Авыл хуҗалыгы министрлыгы системасында, коммерция белән шөгыльләнүче фирмаларда эшләп алган.

Марс хатыны Әлфия белән (ул укытучы, хәзерге вакытта декретта) бер малай һәм бер кыз үстерә. Уллары Даниярга 3 яшь, кызлары Алия 8 айлык.

Туган төбәге Кукмарага кайтып Марс башта "Эффект" җирле мәгълүмат-киңәш үзәгенә нигез салган. Хәзер "Агропромышленность комплексы" инвестиция фондына җитәкчелек итә, читтән торып авыл хуҗалыгы институтының экономика факультетында укый.

Махсуслаштырылган җирле "Агропромышленность комплексы" инвестиция фонды

"АПК" дулкыннарында

ИГЪТИБАР!
Газетабызның 24 нче санында Махсуслаштырылган җирле "Агропромышленность комплексы" инвестиция фонды турында хәбәр басылган иде. Без әлеге хәбәрнең барлык укучыларыбызга, бигрәк тә Казанда, Татарстанның Арча, Балтач, Саба, Мамадыш, Әгерҗе, Киров өлкәсенең Нократ Аланы, Малмыж, Кильмез, Лебяжье, Уржум, Удмуртиянең Кизнер, Можга, Сарапул районнарында яшәүчеләргә кагылуын искәрттек. Онытмаган булсагыз, әлеге язмаларны кисеп алып, җыеп барырга киңәш бирдек, сүзнең дәвамы булачак дип ышандырдык.
Бүген редакция башланган теманы дәвам итә. Болар барысы да - сезгә уйланыр өчен азык. Нинди дә булса сораулар туса, редакциягә язып җибәрегез.

- Марс, хәзер әлеккеге СССРда һәм Татарстанда нинди генә фондлар юк. Горбачев фонды, Болгар фонды... Саный китсәң, кул-аяк бармаклары гына җитмәячәк. "Агропромышленность комплексы" инвестиция фонды (алга таба кыскалык өчен "АПК" - ред.) башкалардан нәрсәсе белән аерыла?

- "АПК" - авыл хуҗалыгына йөз тотып төзелгән бердәнбер тармак фонды. Ул авыл җире, авыл кешесе өчен, аның төп максаты - авылны күтәрү. Фонд ныклы һәм ышанычлы нигезгә корылды, чөнки без кисkәнче 7 тапкыр гына түгел, 77 тапкыр үлчәп карадык. "АПК"ны гамәлгә куючылар - зур абруйлы предприятие башлыклары, банк директорлары, тәҗрибәле белгечләр һәм эшлекле элемтәләре зур булган даирә вәкилләре - барлыгы 134 кеше. Башка фондлардан аермалы буларак, безнең эшнең нигезе хосусыйлаштырылучы дәүләт милкен бүлешүгә корылмаган, без үзебез яңа милек булдырырга омтылабыз. Шул максаттан чыгып, авыл хуҗалыгы продуктларын эшкәртү буенча кечкенә предприятиеләр төзүгә акча кертәчәкбез.

- Мәсәлән?

- Мәсәлән, бүгенге көндә Финляндиянең FEXIMA engineering сәүдә вәкиллеге ягыннан рәхәтләнеп кабул итәрлек тәкъдимнәр бар. Шуларның берсе - көненә 5 тонна сөт эшкәртүче кечкенә завод. Әлеге предприятие полиэтилен капчыкта көненә 2000 литр сөт (майлылыгы 3,7%), 2500 литр кефир (3,7%) һәм полистирол стаканда 500 литр каймак (20%) эшләп чыгарачак.

Бу заводны сатып алу өчен 635 ваучер һәм 1 млн. сум акча кирәк. Яңа сату-алу бәяләреннән чыгып исәпләгәндә, тотылган чыгымнар 275 көндә капланачак.

- Кызыктыргыч мисал. Мондый заводларның бүтән төрләре дә бармы?

- Тагын сменага 2-2,5 тонна макарон җитештерүче, 10 тонна балык эшкәртүче, көненә 400 кг. сыр эшләп чыгаручы, сменага 2 тонна ит эшкәртеп, кәтлит, фарш, колбаса, сосиска ише продуктлар бирүче кечкенә заводлар сатып алырга мөмкин. Шунысы да бик әһәмиятле, бу кечкенә заводлар өчен әллә кайлардан чимал ташыйсы юк, чөнки ите дә, сөте дә, ярмасы да, оны да - авылның үзендә. Җитмәсә, авыл кешеләре өчен өстәмә эш урыннары да барлыкка килә.

- Фонд тагын нинди юнәлешләрдә эш йөртергә исәп тота?

- Үсемлекчелек һәм терлекчелек предприятиеләрен үстерүгә акча кертәчәкбез, фермерларга булышачакбыз. Хәзерге шартларда дәүләт фермерларга күтәрелеп китү өчен банклар аша ышанычлы ярдәм күрсәтә алмый. Ә фонд исә кече механизация чаралары белән булышлык итүне күздә тота.

"АПК" болардан тыш акчасын торак йортлар һәм производство бинаплары төзелешенә, җиңел промышленностька, элекке кулланучылар кооперациясе системасына кертәчәк, муниципаль милекне сату аукционнарында катнашачак, кыйммәтле кәгазьләр сатып алачак һ.б.

- Марс, белүемчә, "Агропромышленность комплексы" инвестиция фондының 32 миллион Устав капиталы бар. Сез бу акчалар белән нишлисез?

- Фондны оештыручылар керткән акчалардан тупланган бу сумма эш өчен кирәкле җиһазлар алуга, фондның вәкилләкләрен ачуга, акцияләр чыгаруга китә. Шуннан без әлеге акцияләрне сатып миллиард сум акча җыябыз. Ә бер елдан безнең акцияләр хуҗаларына табыш китерә башлый.

- "АПК" акцияләре күпме торачак?

- Фонд чыгарган акцияләрнең беренче мең данәсе льготалы шартларда сатылды. Бер хосусыйлаштыру чегына һәркайсы 1500 сумлык 10 акция бирелде. Ләкин шартлар үзгәреп тора. Газета чыккан көннән башлап бер чек һәм 450 сумга 9 акция биреләчәк. Яңалыклар һәм үзгәрешләр хакында без сезнең ярдәм белән укучыларга хәбәр итеп торырбыз.

- Марс, монысы да ифрат кызыктыргыч. Ләкин шунда ук сорау туа: ә гарантияләр нинди?

- Әйдәгез, вариантларны карап китик. Хәзерге вакытта хосусыйлаштыру чеклары бер тиенлек файда китермичә, гап-гади кәгазь булып кешеләрнең өйләрендә ята. Укып - ишетеп белүебезчә, чекларны 1 литр аракыга алыштыручылар булган. Ә күпме кеше чекларын урам һәм базар сәүдәгәрләренә шалкан бәясеннән сатып җибәрде. Кайберәүләр "ныклы гарантиягә": процентлар алып торачаксыз", дигән вәгъдәләргә ышанып, чекларын билгесез коммерция фирмаларына тапшырдылар. Чеклар җыелып беткәч әлеге фирмалардан җилләр исте. Ә кулындагы ваучерын хосусыйлаштыручы предприятиегә керткән кешегә кем нинди гарантия бирә? Предприятиеләрнең ким дигәндә 40%ының хосусыйлаштырылганнан соң банкротлыкка чыгачагына аз гына да шикләнмәскә мөмкин.

- Гарантия дигәннән, искә төшерик, кешеләрнең саклык кассаларындагы акчалары белән нәрсә булып бетте? Югыйсә, иң ышанычлы урында, дәүләт саклавы астында иде бит алар. Кыскасы, әлеге мисаллардан чыгып, бүредән курыккан урманга бармый дип әйтергә була.

- Әйе, ваучер хуҗаларына тәвәккәллек күрсәтер өчен җирлек җитәрлек. Әмма безнең очракка килсәк, биредә "яну" ихтималы аз. Чөнки "АПК" инвестиция фонды үзенең капиталын, ким дигәндә, 20 зур һәм ышанычлы тармакка кертә. Болар - алмаз һәм алтын, нефть һәм газ, урман һәм җир, күчемсез милек һ.б. Шуңа күрә без аякта ышанычлы басып торабыз.

- Марс, югарыда әйтелгәннәр укучыларыбызга "сеңдерә" торыр өчен җитәрлек булгандыр. Әңгәмәң өчен рәхмәт. "АПК" дулкыннарында бу актуаль темага сөйләшү, шөт, әле тагын дәвам итәр.

- Фонд газета укучыларының безнең эшчәнлеккә кагылышлы теләсә-нинди сорауларына бик теләп җавап бирәчәк.

Хөрмәтле укучыларыбыз!
Алдагы саннарда без түбәндәге сорауларга тәфсилле аңлатма биреп китәргә тырышырбыз:
1. Нәрсә ул хосусыйлаштыру чегы һәм аны ничек кулланса отышлырак?
2. Нәрсә ул инвестиция фонды һәм ул башка фондлардан кайсы ягы белән аерыла?
3. Нәрсә ул акция?

Штирлиц исеме белән бәйле көлдергечләр

Геринг һәм аның хатыны йокларга ятарга әзерләнеп йөриләр.

Көтмәгәндә-уйламаган да бүлмәгә Штирлиц килеп керә һәм, шкафны ачып, нәрсәнедер фотога төшерә башлый.

- Бу ниткән хәл?! - дип чәрелдәп җибәрә Герингның хатыны.

- Бу совет шпионы Исаев, - дип җавап бирә ире. - Мегаен, Үзәк боерыгын үтәп йөрүедер.

- Нәрсә карап торасың, кулга ал!

- Файдасы юк, барыбер ычкыну җаен табачак.

* * *

Борман белән очрашуга Штирлиц бугазын ертып "Широка страна моя родная" дигән җыр җырлап килә.

- Сез, Штирлиц, ичмасам бераз конспирация чаралары күрер идегез, - ди Борман, шелтә белән.

- Гафу итегез, партайгеноссе, - дип җавап бирә Штирлиц һәм кара күзлек киеп куя.

* * *

Мюллер бәрәңге алырга китәсе хезмәткәрләрне барлый.

- Мин бармыйм, булмый, - ди Штирлиц.

- Була, - ди Мюллер, кашын җыерып. - Без сезнең хакта барысын да беләбез, аңлатма языгыз.

Хафага төшкән Штирлиц бөтен серләрен ачып, аңлатма язып китерә.

- Һай, бу халыкның әшәкелеге, - дип нәфрәтләнә Мюллер, аңлатманы укыгач. - Бәрәңгегә бармас өчен нәрсәләр генә уйлап чыгармыйлар!

* * *

Штирлиц белән Мюллер машинада баралар.

- Штирлиц, машинаны шулкадәр оста йөртергә сез кайда өйрәндегез? - дип сорый Мюллер.

- ДОСААФта, - дип җавап бирә Штирлиц һәм эченнән генә:"Артыгын ычкындырып ташламадым микән?" - дип уйлап куя.

* * *

Мюллер Штирлицларга кергәч аның кызыл сеқбаш һәм чүәктән йөрүенә игътибар итә.

- Штирлиц, каян алдыгыз бу нәрсәкәйләрне?

- Әнием Кызыл Армия көненә бүләк итте, - дип җавап бирә Штирлиц һәм эченнән генә: "Артыгын ычкындырып ташладым ахры", - дип уйлап куя.

* * *

Мюллер Штирлицның ялганын тотар өчен чираттагы мәкерле сорасын бирә:

- Штирлиц, алай-болай сез яһүд түгелме?

- Юк, мин - урыс, - дип җавап бирә Штирлиц горур тавыш белән һәм эченнән генә уйлап куя: "Чукынды, артыгын сөйләп ташладым, бугай".


Чын ир кеше нишли?

Чын ир кеше хатын-кызлар бәйрәме хөрмәтенә сөйгәненә ***Хәмдүнә ТИМЕРГАЛИЕВА белән Айдар ФӘЙЗРАХМАНОВ*** концертына билет бүләк итә. "Ярый инде шунда" сортына кергән ирләр исә 1-2 мең тәңкәлек хушбуй алып котылалар.

Зур-зур предприятие башлыклары, колхоз-совхоз җитәкчеләре алдында үзләренең чын ир икәнлекләрен исбатлау мөмкинлеге ачыла: бүләк итегез хатын-кызларыгызга бәйрәм кичә! Циркка барып, тамаша кылып, бер җилләнеп кайтсыннар. Билет юнәтү тәртипләрен 32-52-23 яки 32-14-12 телефоннары буенча (цирк) белешә аласыз.

Тамаша вакытында популяр җырчыларга сораулар бирергә мөмкин. Иң кызыклы сорау ияләренә бүләкләр дә әзер. Аларны "Татарстан яшьләре" газетасы һәм "Идел" журналы редакцияләре, "Агропромкомплекс" инвестиция фонды, "Нур" предприятиесе кебек абруйлы оешмалар әзерләде.

Чын ирләр һәм аларның гүзәл ярлары, сезне 7 мартта 17 сәгатьтә цирк бинасында кызыклы тамашага көтәбез.



КАЗАНЫМ.

Евгений КАНАЕВ фотосы.



Казандагы "Радиоприбор" производство берләшмәсе ашханәсеннән 9 шешә коньяк урлаганнар. Спиртлы эчемлек ярaтучы карак тотылган, ләкин ашханәдә хезмәт күрсәтү элеккечә үк калган дип уйларга кирәк.

Республика Дәүләт банкы урам себерүчесе үзенең утырып чыккан шешәдәшен үтергән. Җинаять эшләүченең утлы коралы әлегә табылмаган.

"Казан" аэропорты штурманының фатирыннан 100 мең сумлык эчемлек һәм кием-салым урланган.

Бу сумма икенче бер фатир басу нәтиҗәләре белән чагыштырганда бөтенләй аз булып күренә. Балалар бакчасы мөдире булып эшләүче 28 яшьлек Чаллы кешесенең фатирыннан бик ансат кына итеп 1 миллион 600 мең сум акча һәм алтын балдак урлап чыкканнар. Күрәсең, миллионерлар саны буенча Татарстан озакламый алга киткән капиталистик илләрне дә узып китәр кебек.

Чаллыдагы бу җинаятьне дә заманның гадәти очрагы итеп санарга була. Кою заводы складының стенасын җимереп кергән караклар 2 тонна никель пластина чәлдерәләр. Әлегә бу чималның күпме торганлыгы ачыкланмаган диләр. Ләкин ачыклангач, аның чәчләр үрә торырлык икәнлеген чамалавы авыр түгелдер.

Кемнеңдер миллионнарын урлыйлар, ә кемнеңдер... эчке күлмәген. Менделеев шәһәрендәге базарда беркайда да эшләмәүче ике сукбайны бер ханымның сумкасыннан эчке күлмәген шудыртканда эләктергәннәр.

Әгерҗедәге җирле "Агропромбанк" бинасында без кинолардa гына күреп үскән җинаять эшләнә: билгесез бәрәү милиция сержантының башына өч мәртәбә ата.

Казан - Чаллы юлыннан барганда "КамАЗ" әрҗәсендә 1 миллион сумлык аяк киемнәре өчен әзерләмәләр янып көлгә әверелә.

Вегетарианлык - кешелек тарихының зур ачышы

Бу заманда һәм безнең илдә вегетарианлык турында сөйләү бик үк җиңелдән түгел-түгелен. Безнең туклану турындагы фән озак еллар буе хезмәт ияләрен һәм спортчыларны ризыкның калориялелегенә игътибар итәргә өйрәтеп килде.

Кеше расасының төп өлеше гомер буе тулысынча яки нигездә үсемлек ризыгы белән тукланып яшәгән. Гел ит кенә ашап яшәүче кабиләләр бөтенләй диярлек булмаган да. Хәтта Арктикада яшәүче эскимослар да мүк һәм башка төрле үсемлекләрнең 24 төрен ризык итеп кулланалар. Кеше бүген итне башка бер чорда да ашамаган кадәр ашый.

Ориген калдырган язмаларда да мондый юллар бар: "Мисырлылар ит ашауны зур җинаятькә саныйлар. Алар, мондый җинаять кылганчы, үләргә дә ризалар".

Геродотның язмаларына караганда, мисырлылар җиләк-җимеш-яшелчә ашап яшәгәннәр Болар бар да чи килеш кенә кулланылган. Моны Плиний да раслый.

Исландиядә бөтенләй дә ит ашамаучы кабиләләр булган, анда әле бүген дә шушы йоланы дәвам итүче халыклар бар. Кытай, Һиндстан, Төркия, Борынгы Фәләстиндә дә шул ук хәл күзәтелгән.

Туклану проблемаларын тикшерүче доктор Хиндхед вегетарианнарның сәламәтлеге ит ашаучыларныкына караганда күпкә тазарак һәм гомеренең дә озынрак булуын әйтә. Шушы ук проблемалар белән шөгыльләнүче Маккарисонның раславынча, җиләк-җимеш белән генә тукланып көн күрүче Төньяк Һиндстан хунзалары сәламәтлекләре, физик көчләре һәм гомер озынлыклары ягыннан Җир шарында яшәүче бөтен халыктан да өстен торалар.

Вегетариан-спортчылар спортның күп төрләре буенча рекордчылар, иң күп чыдамлылык соралган ярышларда алар һәрвакыт җиңеп чыга.

Меңнәрчә һәм меңнәрчә авыру кеше, элеккеге туклану рәвешеннән ваз кичеп, вегетариан диетасына яки җиләк-җимеш диетасына күчеп, үз тормышларын саклап калдылар.

Профессор Ришеның раславынча, иттән аермалы буларак, җиләк-җимеш һәм яшелчә лимфа авыруы - анфилаксияне китереп чыгармый. Табигый, итне дә, ит шулпасын да, йомырканы да балага 7-8 яше җитмичә ашатырга һичничек ярамый. Бу яшьтә әле аның мондый төр ризыклардагы токсинны нейтральләштерерлек (зарарсызландырырлык) көче юк.

Ризык никадәр иткә якынрак торса, ул шуның кадәр ашау өчен яраксызрак. Димәк ки, ит - иң начар продукт, аның артыннан йомырка һәм сөт бара. Рак һәм анфилаксиянең үзара уртаклыгы бик күп, чөнки тегесе дә, бусы да аксым белән агулану нәтиҗәсендә барлыкка килә. Хроник анфилаксия галимнәр инде күп еллар буе эзли торган рак маддәседер дә, мөгаен.

Колхоз-совхоз җитәкчеләре колагына!

Предприятие ике телдә (русча һәм татарча) басучы электрлы "Ятрань" машинкасын иткә алмаштыра.

Белешмәләр өчен телефон: 53-07-50.

Байлар өчен генә

"Эффект" җирле мәгълүмат-киңәш үзәге күмәртәләп (оптом) 24 дана "Таврия" җиңел автомобиле сата. Бәяләре икешәр миллион.

Кызыксынучылар булса, мөрәҗәгать итсеннәр: 422110, Кукмара поселогы, Ленин урамы, 28 А, "Эффект" җирле мәгълүмат-киңәш үзәге.

Телефон: (264) 2-24-64

КОТЛЫЙБЫЗ!

ИГЪТИБАР 1000 СУМ!

Бүгеннән башлап котлау белдерүләре бастыру бәясе 1000 сум.

Газетада котлау турында белдерү бастыру өчен редакция счетына 1000 сум акча күчерергә һәм акча күчерү турындагы квитанция белән котлау текстын редакция адресына җибәрергә кирәк. Хатларыгызны бер ай алдан җибәрүегезне сорыйбыз.

* * *

Октябрь районының Яңа Әлмәт авылында яшәүче әниебез Нәбирә Гата кызы Гәрәеваға 64 яшь тулды. Кадерле әниебез! Сине чын күңелебездән туган көнең белән котлыйбыз.

Барлык балаларың исеменнән кызың Алсу.

* * *

Апас районы, Татар Ябалагы авылында яшәүче әниебез Майшәкәр Шакир кызы Гобәйдуллинага 70 яшь тулды. Кадерле әниебез! Сине ихлас күңелдән юбилееең белән тәбрик итәбез, өметле таңнар, куанычлы көннәр, озын гомер һәм ана бәхете телибез. Алдагы көннәрең саулыкта үтсен.

Иң изге теләкләр белән: кызларың, кияүләрең, улың, киленең, оныкларың.

* * *

Барлык мөселман хатын-кызына хас сыйфатларга ия булган сөекле тормыш иптәшем һәм улларымның кадерле әниләре Исламия Сәйфулла кызы Галимовага 41 яшь тулды. Исламия! Без сине чын күңелдән туган көнең белән тәбрик итәбез, озын гомер, ныклы сәламәтлек, киләчәк көннәрең саулыкта, кайгы күрмичә, тыныч, бәхетле үтүен телибез.

Барлык туганнарың исеменнән: тормыш иптәшең, улларың.

* * *

Арча районы, Чиканас авылында яшәүче әниебез Фәһимә Шәйхетдин кызы Зиннәтуллинага 70 яшь тулды. Кадерле әниебез! Без сине ихлас күңелдән олы бәйрәмең белән котлыйбыз, озын гомер, ныклы сәламәтлек, тынычлык, кайгы-хәсрәтсез яшәвеңне телибез.

Иң изге теләкләр белән: улларың, кызларың, киленнәрең, кияүләрең, оныкларың.

* * *

Аксубай районы, Шәрбән авылында туып үскән, хәзерге вакытта Чаллы шәһәрендә яшәүче әтиебез Минвәли улы Зиннур белән әниебез Минзаһит кызы Әлфия Минхаироваларның бергә яшәүләренә 30 ел тулды. Сезгә кояштай озын гомер, саулык-сәламәтлек, шомырт чәчәгедәй ак бәхетләр, алдагы тормыш көннәрегез шатлык-куанычлар белән үтүен теләп калабыз.

Иң изге – теләкләр белән: кызыгыз, киявегез, улларыгыз, киленнәрегез, оныкларыгыз.

* * *

Мамадыш районы, Югары Тәкәнеш авылында яшәүче әбиебез Әдһәмова Шәмсебануга бу көннәрдә 90 яшь, әтиебез Әдһәмов Нәкыйпкә 60 яшь, туганыбыз Рәҗәпкә 30 яшь тулды. Сезне чын күңелдән туган көнегез белән котлыйбыз! Корычтай нык сәламәтлек, кояштай озын гомер, кайгы-хәсрәтсез гомер итүегезне телибез.

Иң изге теләкләр белән: Әдһәмовлар гаиләсе.

* * *

Биектау районының Чыпчык авылында яшәүче кадерле әниебез Гөлирә Гаделша кызы Маннаповага 50 яшь тулды. Әниебезне туган көне белән котлыйбыз, саулык-сәламәтлек, озын гомер телибез.

Иң изге теләкләр белән: кызы, кияве.

* * *

Шәмәрдән поселогында яшәүче әниебез Сөембикә Ханнанованы туган көне белән котлыйбыз. Аңа озын гомер теләп калабыз.

Иң изге теләкләр белән: кызларың, кияүләрең, оныкларың.

* * *

Балтач районы, Балтач авылында яшәүче кадерле әниебез Фәния Нургали кызы Гәрәевага бу көннәрдә 50 яшь тулды. Кадерле әниебез! Сине чын күңелдән олы бәйрәмең белән кайнар котлыйбыз. Сиңа бәхет, кайгы-хәсрәтсез көннәр, саулык-сәламәтлек телибез.

Иң изге теләкләр белән: кызларың.

* * *

Актаныш районы, Күҗәкә авылында яшәүче кадерле әтиебез Мөхтәсәргә 67 яшь тулды, әниебез Фәния Мияссаровага 60 яшь тула. Ә аларның бергә гомер итүләренә 40 ел була. Кадерле әтиебез һәм әниебез! Сезне олы бәйрәмегез белән котлыйбыз. Озын гомер, ныклы сәламәтлек, тыныч тормыш, кайгы-хәсрәт күрмичә тигез яшәвегезне телибез.

Иң изге теләкләр белән: кызыгыз, киявегез,



Баш мөхәррир
Исмәгыйль ШӘРӘФИЕВ
(53-52-34)

ЯЗЫГЫЗ:
420066, Казан, Декабристлар урамы,2.
"Татарстан яшьләре"

ШАЛТЫРАТЫГЫЗ:
53-07-52 - баш мөхәррир урынбасары
53-07-50 - җаваплы сәркатип,реклама
53-07-58 - хатлар бүлеге
53-07-54 - сәяси тормыш һәм тәрҗемә, фән һәм мәгариф
53-07-56 - мәдәният-сәнгать
53-07-52 - табигать, авыл тормышы

"Татарстан яшьләре"н гамәлгә куючылар - ВЛКСМның республика оешмасы, Татарстан Республикасының Яшьләр оешмалары советы, Татарстан Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы.

Газета Татарстан республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында 4-нче номерлы таныклык белән теркәлде.

"Т.Я" сишәмбе, пәнҗешәмбе, шимбә көннәрендә чыга

Редакциягә килгән материаллар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

Газетада язмалары басылган авторларның фикерләре бу әле редакция фикере дигән сүз түгел.

Реклама һәм белдерүләрдәге мәгълүматларның дөреслеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы.

Редакциянең исәп-хисап счеты:
Р/с 700161998/700751 ВКАБ РКЦ ГЦБ г.Казани, МФО 265005
Индекс - 54121
Тираж - 200.000

Татарстан газета-журналлар басмаханәсе. Газета басылуга кул кую график буенча 18 сәгатьтә. Бу санга 14 сәгатьтә кул куелды. Заказ 6060